РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НУРЛАТСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ
РАЙОН
ГЛАВА ЕГОРКИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ЕГОРКИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ Егоркино ав. КАРАР

«10» ноябрь 2021 ел № 7

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Егоркино авыл җирлеге Единение авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Егоркино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Егоркино авыл җирлеге башлыгы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2021 елның 25 ноябрендә 9 сәгать 00 минутка Единение авылы, Лунная урамы 8 нче йорт янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Егоркино авыл җирлегенең Лунная урамы буенча 1-30 нчы йорттан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын уздыруны билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«2022 елда Нурлат муниципаль районының Егоркино авыл җирлеге Единение авылы территориясендә яшәүче, 1нче төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан кала, һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм әлеге акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкару буенча мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

су белән тәэмин итү челтәрләрен норматив хәлгә китерү.

« РИЗА» «КАРШЫ».

3. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Егоркино авыл җирлеге башлыгының«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Егоркино авыл җирлеге Бердәм авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында» 2021 ел, 5 ноябрь, 3нче карары үз көчен югалткан дип санарга.

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ урнаштырырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Каравыл Тавы авылының мәгълүмат стендларында халык җыенын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча игълан итәргә.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Егоркино авыл җирлеге башлыгы А.И. Борисов